РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ИЛТЕРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

КАРАР

Иске Илтерәк авылы

№1 2021 елның 25 гыйнвары

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында" Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Иске Илтерәк авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә **КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6189,10 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2020 елның 30 гыйнвары 57 номерлы карары 2021 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Илтерәк авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: С. Маклаков

Иске Илтерәк авыл җирлеге
башкарма комитеты
җитәкчесе 2021 елның 25
гыйнвары
1 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2021 елның 1 февраленнән.

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтнең бәясе<br>*( сум.)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2284,80 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 920,00 |
| 4. Җирләү (каберне казу һәм мәетне җирләү) | 2984,30 |
| Барлыгы | 6189,10 |

Иске Илтерәк авыл җирлеге
башкарма комитеты
җитәкчесе 2021 елның 25
гыйнвары 1 номерлы
карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 2021 елның 1 февраленнән

| Хезмәтнең исеме | Хезмәтнең бәясе<br>*( сум.)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2.Кәфенләү | 394,00 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китерү | 1890,8 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 920,00 |
| 5. Җирләү (каберне казу һәм мәетне җирләү) | 2984,30 |
| Барлыгы | 6189,10 |